Лилия Дәүләтшина

0+

# Нәниләргә бишек җырлары, бармак уеннары



# Нәниләргә бишек җырлары, бармак уеннары



Казан
Татарстан китап нәшрияты
2015

УДК 821.512.145-1-93:372
ББК 84(2Рос=Тат)-5:74.1
Н89

Төзүчесе *Лилия Дәүләтшина*
Рәссамы *Миләүшә Вазиева*

**Нәниләргә бишек җырлары, бармак уеннары** : ике яшькә
Н89 кадәрге балалар өчен / [төз. Лилия Дәүләтшина ; рәссамы Миләүшә Вазиева]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2015. – 31 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-02931-5

Җыентыкта нәниләргә халкыбызның бишек җырлары, теләк-юраулары, бармак уеннары туплап бирелә. Китап балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән һәм ата-аналарга, балалар бакчалары тәрбиячеләренә тәкъдим ителә.

УДК 821.512.145-1-93:372
ББК 84(2Рос=Тат)-5:74.1

ISBN 978-5-298-02931-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2015
© Дәүләтшина Л. Х., төзү, 2015

# БАЛА ЙОКЛАТКАНДА

## Әлли-бәлли бәү итә[1]

Әлли-бәлли итәр бу,
Йокыларга китәр бу.
Йокыларга киткәчтен,
Бик дәү булып үсәр бу.

Әлли-бәлли бәбкәсе,
Кая киткән әнкәсе?
Каенлыкка җиләккә,
Бәбкәсенә бүләккә.

Әлли-бәлли бәү итә,
Кызым йокыга китә.
Кызым йокыга киткәч,
Әнисе кайтып җитә.

Әлли-бәлли итәргә
Ал бишеге бар аның.
Тәмле йокы теләргә
Үз әнисе бар аның.



[1] Авторлары күрсәтелмәгән шигырьләр татар халык авыз иҗаты үрнәкләреннән алынды.



## Бишек җыры

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

*Габдулла Тукай*

## Бишек җыры

Әлли-бәлли ит, улым,
Карлыгачым, былбылым,
Гүзәлләрнең гүзәле,
Йөрәгемнең үзәге.

Иркәли әнекәең,
Тыныч бул, бәгырькәем.
Син – җәүһәрем, күз нурым,
Карлыгачым, былбылым.

*Мөхәммәт Садри*

## Бишек җыры

Әлли-бәлли, чәчәгем,
Бәллүр мәллә бишегең?
Йоклачы эреп кенә,
Матур төш күреп кенә.

Төшеңдә дә яныңда
Булыр әти-әниең,
Иң-иң тәти курчагың,
Иң-иң тәмле мәмиең.

Иртән сине ал кояш
Назлый-назлый уятыр.
Сөя-сөя, һәммәсе
Иң-иң иркә сүз әйтер.

Мин дә назлап сөярмен,
Шатлыгым син, диярмен.
Бәхетле бул, дәү үс, дип,
Изге теләк теләрмен.

*Әхмәт Ерикәй*







## Бәлли-бәү

Акбай, Акбай, өрмә син!
Тавышланып йөрмә син!
Кызым белән без икәү
Йоклыйк инде, бәлли-бәү.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Минем кызым – курчагым

Әй акыллы курчагым,
Йом күзеңне, бәлли-бәү.
Башка бер сүз дә дәшмим,
Йоклап алыйк без икәү.

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Ай нәни

Күк күгәрчен очадыр,
Зәңгәр күкне кочадыр.
Минем улым бәү-бәү итә,
Йолдызларга очадыр.

Әлли-бәлли бәү, нәни,
Йоклап китәр бу бәби.
Җылы моңнар канатында
Үсеп җитәр бу нәни!

Күгәрченнәр күкләрдә
Очалар җим чүпләргә.
Үсеп җиткәч, минем улым
Үрнәк булыр күпләргә.

*Әхмәт Гадел*





## Диләрә

Бик нәни кыз әле Диләрә,
Ул бары тик бишектә тирбәлә.
Көлә ул «нәнәм» дип сөйгәнгә,
Йоклый ул «әлли-бәү» дигәнгә.
Ул шулай, тирбәлә-тирбәлә,
Дөньяда яшәргә өйрәнә.
Аңлатып йокысы туйганын,
Суза ул бик нәни кулларын.

*Әминә Бикчәнтәева*



# БАЛАНЫ ЙОКЫДАН УЯТКАНДА



* * *

Таң, таң ата, таң ата,
Сагышлы ай да бата.
Кояш нурына күмелеп,
Бәбкәем йоклап ята.

Уян, балам, тиз уян,
Качып китте төн-куян.
Йомшак кына чәчләреңнән
Сөеп, иркәләп куям.

Тор, тор, кызым, тор инде,
Йокың туйгандыр инде.
Син яраткан курчакларың
Күптән торганнар инде.

Үтеп китте кара төн,
Алда якты, матур көн.
Бәхетле булсын таңың,
Әйдә, балам, уйна, көл!

# БАЛАНЫ «ҮС-ҮС» ИТТЕРГӘНДӘ



* * *

Үс-үс, үс-үс итә,
Балам үсеп тә җитә.
Казлар канат бирсен,
Торналар аяк бирсен.

Сузылсын, су буе булсын,
Киерелсен, киртә буе булсын.
Бәхетле, тәүфыйклы булсын,
Ата-анасына шәфкатьле булсын.
Үс-үс-үс-с-с!

Әбисенә, бабасына,
Атасына, анасына
Шәфкатьле бала булсын,
Сүзе үтемле булсын,
Үзе сөйкемле булсын.
Үс-үс-үс-с-с!

# БАЛАНЫ ҮЧТИ-ҮЧТИ СИКЕРТКӘНДӘ




* * *

Үчтеки, үчтеки,
Үсмәгәнгә кечтеки.
Үсә-үсә зур булыр,
Бигрәк матур кыз булыр
*(кызларга)*,
Бик батыр егет булыр
*(малайларга)*.

## Үчти-үчти

Үчти-үчти үчтеки,
үсте китте кечтеки.
Үсте-үсте – зур булды,
таза һәм матур булды,
акыллы, зирәк булды,
һәркемгә кирәк булды.

*Ренат Харис*

# БАЛАНЫ ЧӘБӘК-ЧӘБӘК ИТТЕРГӘНДӘ

* * *

Чәбәк-чәбәк әбкәсе,
Кая киткән әнкәсе?
Каенлыкка җиләккә,
Кызыбызга бүләккә.

* * *

Нәни кызым төймә күк,
Кечкенә генә тәңкә күк,
Алма, алма, алма күк,
Кечкенә генә салма күк.

## Без чәбәкәй итәбез

Чәп-чәп, чәбәкәй,
Безнең Солтан бәләкәй.
Ул акыллы, ул тәтәй,
Килмә монда, кәҗәкәй!

*Нурия Измайлова*





## Чәбәкәй

Минем сеңлем Тәнзилә
Әлегә бик бәләкәй.
Ә шулай да инде ул
Итә беләә чәбәкәй.

Менә шулай, менә шулай
Итә белә чәбәкәй.

Әллә инде шуңарга
Сеңлем бигрәк сөйкемле.
Чәбәк-чәбәк иткәндә,
Очып китәр шикелле.

Менә шулай, менә шулай
Очып китәр шикелле.

*Хәкимҗан Халиков*

# БАЛАНЫ ЮЫНДЫРГАНДА

* * *

Суы сарыксын,
Үзе калыксын,
Ятып йокласын,
Торып уйнасын,
Елап тормасын,
Елак булмасын.





Суы сарыксын,
Үзе калыксын,
Тигез канатлы булсын,
Озын гомерле булсын,
Игелекле, шәфкатьле
булсын.

Суы сарыксын,
үзе калыксын,
Бәхетле,
тәүфыйклы булсын.
Ата-анасына
шәфкатьле булсын,
Олыга-кечегә
мәхәббәтле күренсен.

Салкын су, чиста су,
Баламның битләрен ю,
Баламның күзләрен ю.
Битләре алсулансын,
Күзләре ялкынлансын,
Үзе таза, нык булсын.

# Йомшак су, йөгерек су!

Йомшак су, йөгерек су,
Син мине чиста ю!
Бер тап та калмасын.
Битләрем аллансын.

Авызым елмайсын.
Колагым тыңласын.
Күзләрем күрсеннәр.
Аяклар йөгерсеннәр.

Тешләрем тазарсын.
Кулларым агарсын.
Йомшак су, йөгерек су,
Барын да чиста ю!

*Җәвад Тәрҗеманов*



# БАЛАНЫ ТӘПИ ЙӨРЕРГӘ ӨЙРӘТКӘНДӘ



* * *

Әттә-әттә, әттәти,
Минем улым бик тәти.
Минем улым бик тәти,
Йөреп китәр ул тәпи.

Минем кызым кечкенә,
Бик охшаган үземә.
Әкрен басып, вак-вак атлап,
Кил, күз нурым, үземә.

Тәпи-тәпи килә ул,
Минем янга җитә ул.
Тәпи йөреп зур үскәч,
Мәктәпләргә китә ул.





## Беренче адымнар

Илгиз нинди үскән бала:
Үзе торып баса ала!
Батыраеп атлап китә,
Аяклары тып-тып итә.

Әй күңелле була аңа!
«Тәпи йөрим!» дип куана.

*Әнәс Кари*

## Тәп-тәп бас

Әйдә, улым,
Киттек тәп-тәп!
Атлап шәп-шәп,
Таза бас!
Тәп-тәп атла,
Җәлт-җәлт атла,
Ялгыш басма,
Ипләп бас.

*Хәлим Исмәгыйлев*

# БАЛАНЫ БИЕТКӘНДӘ



## Бии-бии үс әйдә

Ары да килеп биисең,
Бире дә килеп биисең.
Яңа гына тәпи йөреп
Киткәнеңне белмисең.

Бигрәк матур биисең шул,
Кечкенә Гөлсинәбез.
Егылсаң да еламыйсың,
Сине шуңа сөябез.

Сиңа бер яшь тулганына
Өч ай гына бит әле.
Биеп кенә, җырлап кына
Тизрәк үсеп җит әле.

*Әминә Бикчәнтәева*


# БАЛАНЫ УЙНАТКАНДА



## Кәккүк, чыпчык

Кәккүк, чыпчык,
Тәрәзәдән очып чык.
Галиянең өстенә
Матур күлмәк биреп чык.
Кәккүк, чыпчык,
Минем матур кызыма
Тәмле прәннек алып чык.

* * *




Бу бармак – бабай,
Бу бармак – әби,
Бу бармак – әти,
Бу бармак – әни,
Бу бармак – бәби,
Аның исеме – Чәнти.

* * *



Баш бармак,
Балан ияк,
Урта тияк,
Әби-чәби,
Нәни бәби.

* * *



Олыга – утын ярырга,
Ә сиңа – чыгып алырга.
Уртага – мичкә ягарга,
Ә сиңа – казан асарга.
Чәнчәгә – җырлый башларга,
Дусларның күңелен ачарга.



* * *

– Бармак, бармак,
Кайда булдың?
– Бу абый белән урманга бардым.
Бу абый белән кырда йөрдем.
Бу абый белән ботка ашадым.
Бу энем белән җыр җырладым.





* * *

Карга килгән – казан аскан,
Чыпчык килгән – бәрәңге әрчегән,
Торна килгән – камыр баскан,
Сыерчык килгән – аш бушаткан,
Тилгән килгән – бүлгән,
Моңа биргән, моңа биргән,
Моңа биргән, моңа биргән
*(Чәнти бармакка җитеп)*,
Моңа бирмичә калдырган.











* * *


Чакырабыз кәҗәне:
– Кәҗ-кәҗ-кәҗ!
Кәҗ-кәҗ-кәҗ!





* * *


Чакырабыз маэмайны:
– Маһ-маһ-маһ!
Маһ-маһ-маһ!






## «Песием, песием...» уены


Песи, песи, пескәем,
Келәткә кермә, бал ашама;
Базга төшмә, май ашама,
Прес, прес, прес!





* * *

Чакырабыз аткайны:
– Бах-бах-бах!
Бах-бах-бах!






## Бәти

Бар белгәне – «бә».
«Бә» дә «бә», ди ул.
«Бу ни?» – дисәгез,
Безнең бәти ул.


*Рафис Корбан*



## Бармаклар

Уң кулда биш бармак бар,
Сулында да биш бармак.
Ике кулныкын да кушсаң,
Ничәү була, уйлап тап!


*Гөлфия Юнысова*



## Очты, очты...

Очты, очты, каргалар очты!
Башта кара каргалар очты!
Аннан ала каргалар очты!
Аннан бала каргалар очты!

*Равил Фәйзуллин*






## Куянкай

Әй куян, куян,
Кечкенә генә,
Бик йомшак кына,
Бик куркак кына.
Ике колагы
Озынкай гына,
Аягы җиңел –
Мамыккай гына...

*Нәкый Исәнбәт*








* * *

Тук-тук, тукран,
Тукылдатып утырам.
Агачтагы кортларны
Барсын чүпләп бетерәм!



## Әтәч


Таң  ата бугай,
Әтәч кычкыра:
– Кикри-күк,
Кикри-күк!

Йә сузып кына,
Йә бик еш кына:
– Кикри-күк,
Кикри-күк!

*Муса Җәлил*




## Чебиләр



Өйалдында чебиләр
«Чип-чип-чип!» дип йөриләр.
Кечкенә канатлары,
Муеннары сап-сары.


*Мәхмүт Хөсәен*



## Тавык

Мин – тавык, тавык, тавык!
Ак тавык, матур тавык!
Нәни чебиләремә
Корт җыйдым бирәр савыт.

*Гөлнур Корбанова*



## Казлар, казлар...


Казлар, казлар, га-га-га,
Әйдә киттек елгага.
Чумып-чумып йөзәрбез,
Чиста булдык, диярбез.


*Касыйм Тәхау*

* * *

Әкәм-төкәм,
Чыгар мөгезең, чыгар мөгезең,
Тәти кашык бирермен,
Тәмле ботка бирермен.








## Яз

Туктап сана,
Тамчы тама:
Тып, тып, тып.
Төшә-төшә,
Бозны тишә:
Тып, тып, тып.

*Шәүкәт Галиев*



## Йә, алар кемнәр икән?

Тезелешеп кайталар,
«Бак-бак-бак» дип әйтәләр.
Йә, алар кемнәр икән? –
Алар үрдәкләр икән.

*Дамир Гарифуллин*



## Туп

Туп һәрвакыт түгәрәк,
Йөрер өчен тәгәрәп.


*Галимҗан Гыйльман*


## Туп-туп тубыбыз

Туп-туп тубыбыз,
Син – безнең матурыбыз.
Тишмәбез дә югалтмабыз,
Оста тота кулыбыз.

Туп сикерә, син дә сикер,
Тыпыр-тыпыр тыпырда.
Дуслар белән уйна бергә,
Читтә генә утырма.

*Әминә Бикчәнтәева*





# Эчтәлек

Бала йоклатканда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Баланы йокыдан уятканда . . . . . . . . . . . . . . 9
Баланы «үс-үс» иттергәндә . . . . . . . . . . . . . . 10
Баланы үчти-үчти сикерткәндә . . . . . . . . . . . 11
Баланы чәбәк-чәбәк иттергәндә . . . . . . . . . . . 12
Баланы юындырганда . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Баланы тәпи йөрергә өйрәткәндә . . . . . . . . . . 17
Баланы биеткәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Баланы уйнатканда . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20



9 785298 029315